| СОВЕТ ШУБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШУБАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2020г. № 12

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Шубан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодекслары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Шубан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Шубан авыл җирлеге» Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Шубан авыл җирлеге» Советың 2019 нчы елның 11 ноябрь 115 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Шубан авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 42 статьяның 6 пунктында «түләүле документлар» сүзләрен «күрсәтмәләр» сүзенә алмаштырырга.

1.2. 42 статьяның 4 пунктында «түләүле һәм» сүзләрен «казначылык түләүләрен башкару турында күрсәтмәләр белән (алга таба - күрсәтмә) һәм «түләү документлары» сүзләрен « күрсәтмәләр» сүзләренә алмаштырырга.

1.3. 19 статьяның 2 пунктындагы 6 пунктчасында «акчаларны исәпкә алу» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.4. 41 статьяның 2 абзацында «Федераль казначылык органнары счетларыннан» сүзләрен «кертемнәрне исәпкә алу һәм бүлү буенча операцияләрне гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен казначылык счетларыннан» сүзләренә алмаштырырга.

1.5. 40 статьяның 1 пунктындагы 2 абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

1.6. 40 статьяның 1 пунктында «касса керемнәрен» сүзләрен «керемнәре» сүзенә, «касса түләүләре» сүзләрен «акча күчерүләр» сүзенә алмаштырырга, «бюджетның бердәй счетының фаразланучы торышын билгеләү максатларында, вакытлыча касса өзеклеген һәм вакытлыча ирекле чаралар күләмен дә кертеп» сүзләрен өстәргә.

1.7. 19 статьяның 2 пунктындагы 6 пунктчасының 2 абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

1.8. 28 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын күздә тотмаган дәүләт (муниципаль) гарантиясе белән бары тик акцияләренең 100 проценты (өлеше) тиешле муниципаль берәмлекнеке (гарантныкы) булган хуҗалык җәмгыятенең, мөлкәте тиешле муниципаль берәмлек (гарант) милкендә булган муниципаль унитар предприятиенең йөкләмәләре генә тәэмин ителергә мөмкин, ә

гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын күздә тотмаган Россия Федерациясе дәүләт гарантиясе белән шулай ук Россия Федерациясе тарафыннан гамәлгә куелган дәүләт корпорациясе яисә дәүләт компаниясе йөкләмәләре тәэмин ителергә мөмкин.».

1.9. 28 статьяның 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Принципалның кредит (заем, шул исәптән облигацион заем) буенча йөкләмәләрен тәэмин итә торган муниципаль гарантия муниципаль гарантиядә күрсәтелгән гарантның башлангыч язма ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый торган төп йөкләмә шартлары гарантның алдан язмача ризалыгыннан башка үзгәргән очракта һәм (яисә) Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) кредит шартнамәсе һәм кредит буенча муниципаль гарантия бирү турындагы шартнамә нигезендә кредитор тарафыннан кредит акчаларыннан максатчан файдалануны контрольдә тоту гамәлгә ашырыла торган муниципаль гарантия белән тәэмин ителгән кредит (заем, шул исәптән облигацион заем) чараларын максатчан файдаланмаган очракта гына гарант тарафыннан чакыртып алынырга тиеш.

1.10. 27 статьяның 4 пунктындагы 6 абзацында «һәм үтәлә» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.11. 28 статьяның 4 пунктында «һәм үтәлә» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.12. 28 статьяның 16 пунктындагы 5 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

1.13. 7 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) бюджет ассигнованиеләренә түбәндәге ассигнованиеләр керә:

1) казна учреждениеләре функцияләрен үтәүне тәэмин итү, шул исәптән физик һәм (яисә) юридик затларга муниципаль хезмәтләр күрсәтү (эшләр башкару);

2) бюджет һәм автоном учреждениеләргә субсидияләр бирү, алар тарафыннан дәүләт (муниципаль) биремнәрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирүне дә кертеп;

3) дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирү, шул исәптән күрсәтелгән оешмалар тарафыннан физик һәм (яисә) юридик затларга муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) шартнамәләр (килешүләр) нигезендә;

4) дәүләт (муниципаль) милке объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру;

5) муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу (казна учреждениесе функцияләрен үтәүне тәэмин итү өчен бюджет ассигнованиеләреннән һәм казна учреждениеләре муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләреннән тыш), шул исәптән түбәндәге максатларда:

- дәүләт оборона заказы кысаларында кораллану, хәрби һәм махсус техника, җитештерү-техник билгеләнештәге продукция һәм мөлкәт эшләү, сатып алу һәм ремонтлау;

- дәүләт матди резервына товарлар сатып алу;

- юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга - социаль өлкәдә муниципаль хезмәт күрсәтүләргә муниципаль социаль заказны үтәүне финанс белән тәэмин итү максатларында товарлар, эшләр, җитештерүчеләргә, хезмәтләр күрсәтүчеләргә субсидияләр бирү.».

1.14. 6 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Җирлек Советының тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм бюджет турында карар кертелгәннән соң кабул ителгән муниципаль хокукый актлары нигезләмәләре агымдагы финанс елына һәм план чорына агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә бюджетка үзгәрешләр керткәндә чираттагы финанс елында исәпкә алына.».

1.15. 45 статьяның 1 пунктындагы 2 абзацын «яисә әлеге орган исеменнән Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә эш итәргә вәкаләтле башка зат» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет-ресурсында бастырырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) һәм җирлекнең махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шубан авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Мөҗипов..